КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 25 март г.Казань № 274

«Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан дәүләт кадастр исәбенә алу һәм (яки) хокукларны дәүләт теркәвенә алу турындагы гаризаны һәм аңа теркәлә торган документларны күчмә кабул итү тәртибен һәм Дәүләт кадастр исәбенә алуны һәм (яки) хокукларны дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашырганнан соң, «Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан гариза бирүчеләргә документларны, шулай ук дәүләт кадастр исәбенә алудан һәм (яки) хокукларны дәүләт теркәвенә алудан баш тарту турындагы хәбәрнамәләрне һәм гариза бирүче биргән документларның төп нөсхәләрен курьер алып килеп бирүне гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында

«Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законның 18 һәм 29 статьяларындагы аерым нигезләмәләрне тормышка ашыру максатларында, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы карары белән расланган Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

«Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан дәүләт кадастр исәбенә алу һәм (яки) хокукларны дәүләт теркәвенә алу турындагы гаризаны һәм аңа теркәлә торган документларны күчмә кабул итү тәртибен;

«Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан, дәүләт кадастр исәбенә алу һәм (яки) хокукларны дәүләт теркәвенә алу гамәлгә ашырылганнан соң, гариза бирүчеләргә документларны, шулай ук дәүләт кадастр исәбенә алудан һәм (яки) хокукларны дәүләт теркәвенә алудан баш тарту турындагы хәбәрнамәләрне һәм аның тарафыннан бирелгән документларның төп нөсхәләрен алып килеп бирү буенча курьер хезмәтен башкару тәртибен.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 25 март, 274 нче
карары белән расланды

«Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм
муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге»
дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан дәүләт кадастр
исәбенә алу һәм (яки) хокукларны дәүләт теркәвенә алу турындагы гаризаны
һәм аңа теркәлә торган документларны күчмә кабул итү
тәртибе

1. Бу Тәртип «Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – Учреждение) тарафыннан дәүләт кадастр исәбенә алу һәм (яки) хокукларны дәүләт теркәвенә алу турындагы гаризаны һәм аңа теркәлә торган документларны күчмә кабул итүне (алга таба – күчмә кабул итү) гамәлгә ашыру кагыйдәләрен, аны гамәлгә ашыру өчен түләү күләмен, шулай ук мондый түләүнең алынмый торган очракларын билгели.

2. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы карары белән расланган Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрендәге $4^1$ пунктында каралган, Учреждение хезмәткәренең гариза бирүчегә бару юлы белән гамәлгә ашырыла торган күчмә кабул итү, бу пунктта күрсәтелгән очраклардан тыш, түләүле нигездә гамәлгә ашырыла.

Гариза бирүчеләрдән гариза һәм документлар алу өчен күчмә кабул итүне гамәлгә ашыру өчен түләү күләме бер дәүләт хезмәте күрсәтү өчен 1 200 (бер мең ике йөз) сум күләмендә билгеләнә. Гамәлгә ашырыла торган күчмә кабул итү кысаларында гариза бирүчеләрдән өстәмә гаризалар һәм документлар алу өчен түләү күләме 700 (җиде йөз) сум күләмендә билгеләнә.

Күчмә кабул итү өчен түләү хезмәт күрсәткәнгә кадәр дә, аны күрсәткән урында да (хезмәт күрсәтү вакытында техник мөмкинлек булганда, гариза бирүче тарафыннан финанс-кредит оешмалары бүлекләре аша түләү очракларыннан башка) акчалата һәм акчалатасыз башкарылырга мөмкин.

Күчмә кабул итү түбәндәге категорияләрдәге гариза бирүче гражданнар өчен түләүсез гамәлгә ашырыла: тиешле документларын күрсәткәндә Советлар Союзы Геройлары, Россия Федерациясе Геройлары, Дан орденының тулы кавалерлары, «Ватан алдындагы казанышлар өчен» орденының тулы кавалерлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, Россия Федерациясе Хезмәт Геройлары, Хезмәт Даны орденының тулы кавалерлары һәм аларның тол хатыннары (тол ирләре), Бөек Ватан сугышы ветераннары, Бөек Ватан сугышы инвалидлары, инвалид балалар, инвалид балаларның законлы вәкилләре, балачактан I төркем инвалидлары, I һәм II төркем инвалидлары, күп балалы гаиләләр әгъзалары (ата-аналар, уллыкка алучылар,

опекуннар (попечительләр) һәм аларның балалары), 80 яше тулган һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге гражданнар.

3. Гариза бирүче Учреждениегә шәхсән йә телефон элемтәсе аша Учреждение хезмәткәре тарафыннан гариза бирүченең яшәү урыны буенча гамәлгә ашырыла торган күчмә кабул итүне оештыру турында заявка белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Күчмә кабул итүне оештыру турындагы заявкада түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

күчмә кабул итүне гамәлгә ашыру урыны адресы, күчмә кабул итү датасы һәм вакыты (Учреждениенең эш режимын, язылу өчен буш даталарын һәм вакытын исәпкә алып), исәпкә-теркәүгә алу гамәленең төре, күчемсез мөлкәт объектлары саны;

гариза бирүче физик затлар (индивидуаль эшмәкәрләрне кертеп) өчен шулай ук фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), элемтәгә керү өчен мәгълүматлар (телефон номеры, электрон почта адресы), бу Тәртипнең 2 пункты нигезендә гариза бирүченең ташламаларга хокукы булу турында мәгълүмат хәбәр ителә;

гариза бирүче юридик затлар өчен шулай ук юридик затның исеме, урнашу урыны адресы, ОГРН, ИНН, КПП, элемтәгә керү өчен мәгълүматлар (телефон номеры, электрон почта адресы) хәбәр ителә.

Күчмә кабул итүне гамәлгә ашыру өчен бирелгән мәгълүматлар мөрәҗәгать ителгән көнендә күчмә кабул итүне оештыру турындагы заявкаларны теркәү журналына кертелә, аның формасы Учреждениенең локаль хокукый акты белән раслана.

4. Учреждение хезмәткәре тарафыннан гариза бирүчегә барып гамәлгә ашырыла торган күчмә кабул итүдән баш тартылган очракта, гариза бирүче бу турыда Учреждение хезмәткәренең планлаштырыла торган датасына кадәр бер эш көне кала Учреждениегә шәхсән йә телефон элемтәсе аша хәбәр итәргә тиеш. Күчмә кабул итүдән баш тарту турында язу хәбәр ителгән көнендә күчмә кабул итүне оештыру турындагы заявкаларны теркәү журналына кертелә. Баш тарту турында бу пунктта күрсәтелгән сроктан соң хәбәр ителгәндә күчмә кабул итү буенча хезмәт күрсәтелгән дип санала һәм түләнгән акча кире кайтарылмый.

5. Гариза бирүче тарафыннан күчмә кабул итүне гамәлгә ашыру өчен акча артык түләнелгән очракта яки гариза бирүче тарафыннан бу Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән срокларда күчмә кабул итүдән баш тартылган очракта, түләнгән акча гариза бирүченең акчаны кире кайтару турындагы гаризасы нигезендә аны биргән көннән 15 эш көне эчендә кире кайтарыла.

6. Учреждение хезмәткәре түбәндәге очракларда күчмә кабул итүне гамәлгә ашыру мөмкинлеге булмау турында карар кабул итә:

гариза бирүче күчмә кабул итү урыны адресы буенча билгеләнгән датада һәм вакытта 30 минуттан артык булмаганда;

күчмә кабул итү урынына килгәннән соң, гариза бирүче 30 минут эчендә хезмәт күрсәтү өчен кирәкле шартлар (электрга тоташтыру, кирәкле җиһаз) белән тәэмин итмәгәндә;

гариза бирүче күрсәтелә торган хезмәт өчен түләмәгәндә;

гариза бирүче Учреждение хезмәткәренә үз шәхесен раслый торган документларны күрсәтмәгәндә;

Учреждение хезмәткәре гариаз бирүче тарафыннан күрсәтелгән адрес буенча

билгеләнгән вакытта килеп тә, гариза бирүче бер дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану өчен гариза һәм документлар бирүдән баш тартканда яки тайпылганда;

Учреждение хезмәткәре тормышына һәм сәламәтлегенә, шулай ук гариза бирүче яисә гариза бирүче белән бергә булган башка затлар ягыннан куркыныч янаганда, гариза бирүче үзенең кылына торган гамәлләре характерын аңларлык хәлдә түгел яисә наркотик, алкогольле һәм психотроп матдәләр йогынтысында һ.б. булган дип карау өчен нигезләр булганда.

Гариза бирүчегә күчмә кабул итү буенча хезмәтләр күрсәтмәү өчен бу пунктта күрсәтелгән нигезләр булганда, күчмә кабул итү буенча хезмәт күрсәтелгән дип санала, хезмәт күрсәтү өчен түләнгән акча кире кайтарылмый.

7. Учреждение хезмәткәре гариза һәм аңа теркәлә торган документларны дәүләт кадастр исәбенә алу һәм (яки) күчемсез мөлкәткә хокукларны дәүләт теркәвенә алу буенча хезмәт күрсәтүне җайга сала торган закон нормалары таләпләре нигезендә кабул итүне гамәлгә ашыра.

8. Учреждение туберкулез, психиатрия, наркология һәм башка диспансерлар һәм стационарлар, башка махсуслаштырылган медицина оешмалары, психик бозылышлар белән интегүче затлар өчен социаль хезмәт күрсәтүче стационар учреждениеләре территориясенә, шулай ук ябык административ-территориаль берәмлекләр һәм хәрби частьлар, төзәтү учреждениеләре һәм тикшерү изоляторлары территориясенә баруны гамәлгә ашырмый.

9. Учреждение Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең вазыйфаи затлары тарафыннан кабул ителә торган карарлар өчен җавап бирми.

10. Учреждение күчмә кабул итүне Татарстан Республикасы территориясендә Учреждениенең тиешле муниципаль районда транспорт белән тәэмин ителеше булганда гына гамәлгә ашыра.

11. Учреждение күчмә кабул итүне Учреждение бүлекләренең һәм филиалларының эш сәгатьләрендә гамәлгә ашыра.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 25 март, 274 нче
карары белән расланды

«Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан, дәүләт кадастр исәбенә алу һәм (яки) хокукларны дәүләт теркәвенә алу гамәлгә ашырылганнан соң, гариза бирүчеләргә документларны, шулай ук дәүләт кадастр исәбенә алудан һәм (яки) хокукларны дәүләт теркәвенә алудан баш тарту турындагы хәбәрнамәләрне һәм аның тарафыннан бирелгән документларның төп нөсхәләрен алып килеп бирү буенча курьер хезмәтен башкару тәртибе

1. Бу Тәртип «Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан дәүләт кадастр исәбенә алу һәм (яки) хокукларны дәүләт теркәвенә алу гамәлгә ашырылганнан соң, гариза бирүчеләргә кәгазьдә бирелергә тиешле документларны, шулай ук дәүләт кадастр исәбенә алудан һәм (яки) хокукларны дәүләт теркәвенә алудан баш тарту турындагы хәбәрнамәләрне һәм, дәүләт кадастр исәбенә алу һәм (яки) хокукларны дәүләт теркәвенә алу гамәлгә ашырылганнан соң, гариза бирүче тарафыннан бирелгән документларның кәгазьдәге документлар рәвешендә төп нөсхәләрен (алга таба – соңгы документлар) алып килеп бирү буенча курьер хезмәтен башкару кагыйдәләрен, аны гамәлгә ашырган өчен түләү күләмен, шулай ук мондый түләү алынмый торган очракларны билгели.

2. Соңгы документлар Учреждение хезмәткәре тарафыннан «Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законның 29 статьясындагы 13 – 17 өлешләрендә күрсәтелгән затларга (алга таба – гариза бирүче) дәүләт кадастр исәбенә алу һәм (яки) хокукларны дәүләт теркәвенә алу турындагы гаризада (алга таба – гариза) курьер хезмәте күрсәтергә дип билгеләнгәндә, мондый ысулдан файдаланып, тапшырылырга мөмкин.

3. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы карары белән расланган Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 4[1] пунктында каралган, Учреждение хезмәткәренең гариза бирүчегә бару юлы белән гамәлгә ашырыла торган соңгы документларны алып килеп бирү буенча курьер хезмәте, бу пунктта күрсәтелгән очраклардан тыш, түләүле нигездә гамәлгә ашырыла.

Соңгы документларны алып килеп бирү буенча курьер хезмәтен гамәлгә ашырган өчен түләү күләме 950 (тугыз йөз илле) сум күләмендә билгеләнә.

Алып килеп бирү буенча курьер хезмәте өчен түләү хезмәт күрсәткәнгә кадәр дә, аны күрсәткән урында да (хезмәт күрсәтү вакытына техник мөмкинлек булганда, гариза бирүче тарафыннан финанс-кредит оешмалары бүлекләре аша түләү очракларыннан башка) акчалата һәм акчалатасыз башкарылырга мөмкин.

Соңгы документларны алып килеп бирү буенча курьер хезмәте түбәндәге категорияләрдәге гариза бирүче гражданнар өчен түләүсез гамәлгә ашырыла: тиешле документларын күрсәткәндә Советлар Союзы Геройлары, Россия Федерациясе Геройлары, Дан орденының тулы кавалерлары, «Ватан алдындагы казанышлар өчен» орденының тулы кавалерлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, Россия Федерациясе Хезмәт Геройлары, Хезмәт Даны орденының тулы кавалерлары һәм аларның тол хатыннары (тол ирләре), Бөек Ватан сугышы ветераннары, Бөек Ватан сугышы инвалидлары, инвалид балалар, инвалид балаларның законлы вәкилләре, балачактан I төркем инвалидлары, I һәм II төркем инвалидлары, күп балалы гаиләләр әгъзалары (ата-аналар, уллыкка алучылар, опекуннар (попечительләр) һәм аларның балалары), 80 яше тулган һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге гражданнар.

4. Учреждение хезмәткәре, соңгы документлар Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтеннән Учреждениегә кергәннән соң, ике эш көненнән артмаган срокта гариза бирүче белән аның гаризада күрсәтелгән телефон номеры аша документларны алып килеп бирү датасын һәм вакытын килештерә.

Әгәр дә Учреждение хезмәткәре гариза бирүчегә аның гаризада күрсәтелгән телефон номерына шалтырата һәм документларны алып килеп бирү датасын һәм вакытын килештерә алмаса, алып килеп бирү буенча курьер хезмәте күрсәтелгән дип санала һәм хезмәт күрсәткән өчен дип түләнгән акча кире кайтарылмый.

5. Алып килеп бирү буенча курьер хезмәтен гамәлгә ашырганда, Учреждение хезмәткәре гариза бирүчене бирелә торган документлар исемлеге белән таныштыра, гариза бирүчегә документларны бирә һәм распискада (исемлектә), алып килеп бирү буенча курьер хезмәте аша документларның тулы күләмдә алынуын язып, документларны бирү турында билге куя, датасын һәм вакытын, гариза бирүченең фамилиясен һәм инициалларын күрсәтә һәм гариза бирүчегә үз имзасын куярга тәкъдим итә, ахырдан үз фамилиясен, инициалларын һәм вазыйфасын күрсәтеп, имзасы белән раслый.

6. Учреждение хезмәткәре түбәндәге очракларда алып килеп бирү буенча курьер хезмәте гамәлгә ашыру мөмкинлеге булмау турында карар кабул итә:

документлар бирүне сорап, гариза бирмәгән зат (аның вәкиле) мөрәҗәгать иткәндә яисә мөрәҗәгать иткән зат үз шәхесен раслый торган документны күрсәтүдән баш тартканда;

гариза бирүче алып килеп бирү буенча курьер хезмәте урыны адресы буенча билгеләнгән датада һәм вакытта 30 минуттан артык булмаганда;

алып килеп бирү буенча курьер хезмәте күрсәтү урынына килгәч, гариза бирүче 30 минут эчендә хезмәт күрсәтү өчен кирәкле шартлар (электрга тоташтыру, кирәкле җиһаз) белән тәэмин итмәгәндә;

гариза бирүче күрсәтелә торган хезмәт өчен түләмәгәндә;

Учреждение хезмәткәре билгеләнгән вакытта гариза бирүче күрсәткән адрес буенча килеп тә, гариза бирүче соңгы документларны алудан баш тартканда яки тайпылганда;

Учреждение хезмәткәре тормышына һәм сәламәтлегенә, шулай ук гариза бирүче яисә аның янында булган башка затлар ягыннан куркыныч янаганда, гариза бирүче үзенең кылына торган гамәлләре характерын аңларлык хәлдә түгел яисә наркотик, алкогольле һәм психотроп матдәләр йогынтысында һ.б. булган дип карау өчен нигезләр булганда.

Гариза бирүчегә алып килеп бирү буенча курьер хезмәтен күрсәтмәү өчен бу пунктта күрсәтелгән нигезләр булганда, алып килеп бирү буенча курьер хезмәте күрсәтелгән дип санала һәм хезмәт күрсәтү өчен түләнгән акча кире кайтарылмый.

7. Гариза бирүче алып килеп бирү буенча курьер хезмәте күрсәтү урыны адресы буенча билгеләнгән датада һәм вакытта 30 минуттан артык булмаганда, Учреждение хезмәткәре распискада, гариза бирүченең алып килеп бирү буенча курьер хезмәте күрсәтү урыны адресы буенча билгеләнгән датада һәм вакытта булмавы аркасында, аның алып килеп бирү буенча курьер хезмәте аша документларны бирүдән баш тартуы турында язып, билге куя, үз фамилиясен һәм инициалларын, вазыйфасын, датасын һәм вакытын (минутына кадәр төгәл итеп) күрсәтә, үз имзасы белән раслый.

8. Гариза бирүче аңа бирелә торган документлар исемлеге белән риза булмаганда, документларны алудан һәм распискада үз имзасын куюдан баш тартканда аңа документлар бирелми, Учреждение хезмәткәре распискада, гариза бирүченең документларны алудан баш тартуы турында язып, документларны алудан баш тарту турында билге куя, шулай ук үз фамилиясен һәм инициалларын, вазыйфасын яза, датасын һәм вакытын (минутына кадәр төгәл итеп) күрсәтә, үз имзасы белән раслый.

9. Әгәр бу Тәртипнең 4, 6 – 8 пунктларында каралган очракларда гариза бирүче тарафыннан документлар алынмаса, гариза бирүчегә документларны алу өчен Учреждениегә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Әлеге очракларда хезмәт күрсәткән өчен түләү гариза бирүчегә кире кайтарылмаска тиеш.

10. Соңгы документларны алып килеп бирү буенча курьер хезмәтеннән баш тартылган (вакыты үзгәртелгән) очракта, гариза бирүче бу турыда бер эш көне кала Учреждениегә хәбәр итәргә тиеш. Баш тарту турында бу пунктта күрсәтелгән сроктан соң хәбәр ителгәндә алып килеп бирү буенча курьер хезмәте күрсәтелгән дип санала һәм түләнгән акча кире кайтарылмый.

11. Гариза бирүче тарафыннан соңгы документларны алып килеп бирү буенча курьер хезмәтен гамәлгә ашыру өчен акча артык түләнелгән очракта, шулай ук гариза бирүче тарафыннан Учреждение хезмәткәре килү көненә кадәр бер эш көне кала алып килеп бирү буенча курьер хезмәтеннән баш тартылган очракта, түләнгән акча гариза бирүченең акчаны кире кайтару турындагы гаризасы нигезендә аны биргән көннән 15 эш көне эчендә кире кайтарыла.

12. Учреждение туберкулез, психиатрия, наркология һәм башка диспансерлар һәм стационарлар, башка махсуслаштырылган медицина оешмалары, психик бозылышлар белән интегүче затлар өчен социаль хезмәт күрсәтүче стационар учреждениеләре территориясенә, шулай ук ябык административ-территориаль берәмлекләр һәм хәрби частьлар, төзәтү учреждениеләре һәм тикшерү изоляторлары территориясенә баруны гамәлгә ашырмый.

13. Учреждение күчмә кабул итүне Татарстан Республикасы территориясендә Учреждениенең тиешле муниципаль районда транспорт белән тәэмин ителеше булганда гына гамәлгә ашыра.

14. Учреждение алып килеп бирү буенча курьер хезмәтен Учреждение бүлекләренең һәм филиалларының эш сәгатьләрендә гамәлгә ашыра.

---